# Бала диеп яши җирдә Ана!

Халкыбыздагы: «Баланың беләге авыртса, ананың йөрәге сызлар» дигән әйтем буш урында барлыкка килмәгән. Ана – газиз баласы хакына тау-ташларны күчерергә сәләтле. Ана – мәгърур кыя сыман баласын җил-давылдан, тормыш зилзиләләреннән сакларга әзер. Баһадирдай батыр, мамыктай йомшак күңелле аналар хакында шагыйрьләр күңел кылларын тибрәндерерлек шигырьләр, поэмалар иҗат итәләр. Рәссамнар гаҗәеп картиналар язалар; язучылар күңел күзен ачарлык, сүнеп барган хәтер учагына "ут элдерерлек" искиткеч әсәрләр тудыралар. Анага һәр заманда да, һәр халыкта да мәдхия укылган, укыла һәм кешелек яшәгәндә укылачак та.

Һәрбер инсан да әнисен кадерләргә, якларга-сакларга тиешлеген искәртү максатыннан ноябрьнең соңгы атнасының якшәмбесе әниләр көне буларак билгеләп үтелә.

Кырыс чорларда, еллар ябык булганда, кесә такыр булганда, ана кеше төп кешелек сыйфатын күрсәтте һәм күрсәтә. Ана – соңгы телем ипекәен баласына каптыра – тик исән булсын дип, тик исән булсын дип, газизләрдән газиз баласы. Ана, ачтан хәлсезләнсә дә, өшесә-туңса да, иң беренче булып баласын кайгырта.

Ахирәткә күчкән әниләрнең каберен белик һәм даими рәвештә алар рухына догалар кылыйк. Исән булганнарының кадерен белик!

Балачакка кайтаручы, хатирәләр белән күңелне йомшартучы шушы бәйрәм уңаеннан Иштирәк авылында яшәүче изге күңелле Асия Метшина һәм Новотроицкое авылында яшәү ямен тоеп, инде үзләре күптән әби-бабай булган җиде баласы, кияү-киленнәре һәм күп онык-оныкчыклары белән гөрләшеп яшәүче Асия Хәсәнованың шигъри тәлгәшләрен бәйрәм күчтәнәче итеп кабул итегез.

**Зәрия Вәлиева.**



**Әнигә**

Әни дигән кеше бер генә ул,
Әни дигән сүз дә бер генә.
«Әннә» диеп телләр ачыла,
Әни диеп үзәк өзелә.

Әни дигән сүзне әйтим дисәң
Кирәк яннарыңда торырга.
Күп сабырлык, сәламәтлек кирәк
Балаң өчен әни булырга.

Яшәргә дә җирдә, эшләргә дә
Әни булгач җиңел була ул.
Бу дөньяның яме, яшәү тәме
Янда әни булганда гына ул.

**Сугыш чоры балалары**

Сугыш чоры балалары булып
Ачлык-ялангачлыкны күреп
Үскәнгәдер балачакта
Онытылмый картайгач та
Әти-әни, бабамнарның
Җылы сүзе, догалары.
Әниемнең кешеләргә
Яхшылыклар гына кылуы,
Ихласлыгы, якты күңеле –
Олы үрнәк булды һәммәбезгә,
Үгет-нәсыйхәте гомер буе
Маяк булды язмыш сукмагыннан
Адашмыйча, туры үтәргә.
Гомер буена рәхмәтлемен
Барысы-барысы өчен дә
Әнием – изге күңелле
Җирдәге иң кадерле кешемә.
Инде картлыкка җитсәм тә
Тәрбияли, сабырлыкка өнди
Әниемнең сүзе, васыяте
Кайчакларда кызып киткәндә.
Әти-әни, бабамнар сүзе
Тәрбиядә өстен торды.
Олы тормыш юлларында
Туры юлдан тайпылмаска
Янып торган маяк булды.

**Онықчыгыма**

Балам баласы килгән
Матур итеп киенгән.
Әби-бабасының хәлен
Белергә диеп килгән.
И-и, бабаем, әбекәем!
Тәмле чәйләрең димен
Эчеп сыйланам әле,
Идәннәрең юамын –
Яратам мин юарга.
Сөйләгәнне – тыңларга.
Моңлы көйгә кушылып
Татар җырын җырларга.
Сезгә килеп ярдәм итсәм,
Идәннәр юып китсәм
Сөенәмен үзем дә –
Изгелек кайтыр үземә.
Яратамын сезнең белән
Тәмле чәйләр эчәргә.
Сезнең яныгызга килеп
Эшкә өйрәнеп үсәргә.
Балалар килеп керсәләр
Өй шатлык белән тула.
Сөйләшәбез-серләшәбез
Оныклар тәтелдәп тора:
– Әбекәем, утыр әле
Чәчләреңне үрәем,
Мин бит сине әбекәем
Бик, бик якын күрәмен.
Сөйлә әле үткәнеңне
Ничек үсеп җиткәнеңне,
Аннары, кияүгә киткәнеңне.
Күп бала китергәнсең,
Челтәрләр бәйләгәнсең,
Чигүләреңне дә чигеп
Ничекләр җитешкәнсең?!
Тал бишектә тирбәтеп
Моңлы көйләрең көйләп
Үстергәнсең балаларың
Изге теләкләр теләп.
Сез бит әбием, бабай белән
Пар аккошлардай охшаш!
Яшәсәм иде мин дә
Тик сезгә генә охшап.

**Солдат аналарына**

Кара болыт булып кайгы килде
Тыныч яшәп яткан илемә.
Илен саклар өчен ир-егетләр китте
Мылтык асып көчле иңенә.

Ничә еллар сугыш барды
Күпме ятим елап калды,
Ә батырлар баш имәде
Хәтта Берлинны алды.

Үткәннәрнең әче газаплары
Әле һаман истә, онытылмый.
Солдат аналары искә алып
Шул елларның җырларын җырлый.

Солдат аналары горур булып
Гомер итә туган илендә.
Ул елларда кайгы килгән чакны
Онытмыйлар алар бүген дә.

**Асия Хәсәнова,**
**Новотроицкое авылы.**

**Кадерлә син Ананы!**

Авыр сүзләр әйтмәгез сез
Тапкан-баккан анага!
Синең хакка ял итмичә
Көч түккән ана бит ул.
Ризыкның такы-токы
булган чакларында да
Иң тәмлесен сиңа сузган,
иң юмарт ана бит ул.
Көйсезләнеп еласаң
Күз яшең сөртеп юаткан,
Иң сабыр ана бит ул.
Бишек җырларын көйләгән,
Төн йокысын калдырган
Миһербанлы ана ул.
Сый-нигъмәтләрен сиңа
Биргәненә сөенгән
Киң күңелле ана ул.
Әниеңне хөрмәтлә син –
Бел аның кадерләрен!
Ана хакын хакласаң
Булыр бәхеткәйләрең!

**Дәүләтле булсак иде**

Дәүләт – хикмәтле сүз ул –
Аңлата – мөстәкыйль илне.
Татарда дәүләт дигән сүз
Аңлата – мал-мөлкәт, байлыкны.
Байлык бар ул безнең илдә:
Җир өстендә һәм астында.
Ни генә юк туган җирдә,
Барысын биргән Раббым безгә!
Нәфесеңне тезгендә тотып
Тота белсәң байлык җитә:
Сиңа, миңа, аңа һәм аларга.
Шуны аңламый кайберәүләр
Булалар нәфес колы,
Үз кесәсен генә кайгырта,
Талый, урлый, комсызланып
Җыя булган бар байлыкны.
Илдә булган, җирдә булган
Бар байлык – халыкныкы!
Дәүләтле булсак иде! –
Иманыбызны үстереп,
һәм дә телебезне саклап,
Милләт буларак без җирдә
Сакланып калсак иде!

***

Кризис диләр, кризис диләр
Ул соң кемгә ошасын?!
Аның ачысын татымас өчен
Һәркем үзе тырышсын!
Һәркем эшләп ашасын!
Кырларда икмәк үссен,
Мичтә кабарып пешсен.
«Эшлимен дә ашыймын!» диеп
Кеше сөенеп йөрсен.

***

Инешләр үргә акмыйлар
Ага алар түбәнгә таба.
Үргә акмаса да инешләр
Юл алалар зур дәрьяга.

***

Карлар кунды инде чәчләремә
Эремәсләр язлар килсә дә.
Их! Гомерләр бик тиз үтә икән,
Ярсу яздай йөрәк типсә дә.

***

Гомеремнең көзенә кердем –
Яфрак булып коела елларым,
Алтын көздә җыям уңышларым –
Балаларым кайта җыелышып,
Онықларым ала кочаклап.

***

Телик хәерле иртәләр
Таңнар аткан чагында.
Изге дога, яхшы кәеф
Булсын һәрчак телебездә.

***

«Мин бәхетле!» диеп һәрчак
Түм-түгәрәк бәхетне
Тартып китерә белегез,
Яшәү ямен белегез!

**Асия Метшина,**
**Иштирәк авылы**